# Нәрсә ул дуслык?

Күрше авылдан йөреп укыганлыктан, калган сүзләребез кайтканда сөйләшергә кала. Уку елы тәмамланырга вакыт бик аз калды, тагын безгә бер ел гына укыйсы кала. Әй, өзелеп сагынырбыз әле без бу елларны, сыйныфташ дусларны… Ә инде чын дус дип аталучы бер генә

**Дөньяда ялгызлыктан да авыр нәрсә юктыр. Шуңа күрә кечкенәдән үк кешеләр белән аралаша, үзеңә дуслар сайлый белергә кирәк.**

Кем соң ул дус? Дус - ул синең сыйныфташың, партадашың, кечкенәдән бергә уйнап үскән күрше кызы, я малае.

Мин үземнең сыйныфташларымның барысын да дусларым дип атар идем. Шуңа күрә дә һәр көнне мәктәпкә барасы килеп тора.

Көндәлек хәлләрне, вак-
төяк проблемаларны
бергәләп сөйләшеп
алабыз, киләчәккә
планнар корган булабыз.